# Төзәлмәс яралар…

1979 нчы елның 12 нче декабре... Бу - Әфганстанга совет гаскәрләренең “тәртип урнаштыру” максаты белән кергән көн. Ун ел барган бу сугыш бик күп гаиләләргә кайгы – хәсрәт китерде. Әфган сугышыннан исән – сау кайткан егетләр йөрәгенә исә төзәлмәс яра салды.

Кукмара районыннан бу сугышта 160 кеше катнаша. 33 әфганчы орден һәм медальләр белән бүләкләнә. Хәрби хәрәкәтләр вакытында Әфганстанда 5 райондашыбыз һалак була. Чит җирләрдә һәлак булган егетләрнең әти-әниләре йөрәгендә яра, сызлану һаман да кимеми...

Әфган сугышының фаҗигасы безнең гаиләбезгә дә бик таныш. Бу сугышта минем әтием катнашты. Әтием бу сугыш турында күп сөйләргә яратмый. Әфган турында сорасам, ул җитдиләнеп, уйчанланып кала. Әтиемнең моңсу яшьле күзләренә карыйм да, аның йөрәк яраларына кагылуыма үкенеп куям. Ул күзләрдә сугышның һәр көне язылып куелган кебек!!!

Туембаш авылында гомер итүче Рәхимә һәм Габделхәй Шиһаповлар гаиләсендә 5 ул, 2 кыз тәрбияләнеп үсә. 1980 нче ел...Олы уллары Габделфәрит армиядә хезмәт иткән вакытта, октябрьдә тагын икесе – Габделфәиз белән Фәнил дә солдатка алына.. Туганнарның берсе – Венгриягә, икенчесе – әтием Фәнил – Әфганстанга эләгә. Ул - Тау батальонында снайпер. Колонналар ике шәһәр арасындагы буш урынга палаткалар корып урнаша. Кышлакларга азык-төлек илтүче колонналар, безнен гаскәрләрне саклап - озатып, айлар буена полкка кайтып кермиләр. Хәбәр булуга, тагын дошманнар һөҗүм иткән урынга кузгалалар, кабат ут эченә керәләр.

1981нче елның 1 ноябрендә аларга Союздан керүче кораллы көчләрне озата бару бурычы йөкләнә. Бертуктаусыз барган бәрелешләрдә миноментлар сафтан чыга, машиналарга шоферлар җитми. Әтием, ике дә уйламыйча, руль артына утыра һәм, кышлак белән тау арасыннан сузылган бердәнбер юлдан барганда, засадага эләгә. Көчле атышлар башлана. БТР лар, танклар минага эләгеп шартлый. Кечкенә генә күперне чыкканда әтинең башы яралана. Пуля

маңгае буйлап аның кашын , күз кабакларын актарып чыгара. Хәле бик авыр булса да, машинасын туктатмый ул, кабинадагыларны төшерергә өлгерә, шуннан соң гына үзе дә җиргә үрмәли. Машинада шартлаткычлар була, алга таба нәрсә булганын  хәтерләми ул, аңсыз хәлдә госпитальгә озатыла. Көндезге өчләрдә башланган  бәрелеш төне буе дәвам итә. Яраланучылар да, үлүчеләр дә күп була.

Авыр яра алган әтиемне  хезмәттән азат итәләр, ләкин ул өйдә кул кушырып утыра торганнардан түгел. Хезмәт белән авыр хатирәләрен  оныту ниятеннән,  әтием Якутия якларына китә, эшкә урнаша. Көндезләрен эш белән юана, төн җитте исә, башы авыртуга түзә алмыйча, дару арты дару йота. Табиблар аңа туган якларына кайтырга кирәк, дип киңәш бирәләр. Кайткач сөйгән кызы – әнием Халидә белән гаилә коралар. Тормышларын тулыландырып, абыем Рәмзил, соңрак мин дөньяга килгәнмен. Әфган җирендә күргән  аврлыкларның берсе дә эзсез югалмый - 1993нче елда әтиемнең йөрәгенә операция ясыйлар.

Әтием - Фәнил Шигапов  - Кызыл Йолдыз ордены кавалеры. Әфганчылар сафында хәрби бурычын батырларча үти алуы белән горурлана, армия хезмәтенә бармый йөреп, күңелен эчеп – исереп йөрүгә биргән ир – егетләрнең күбәюен күреп офтана ул. “Без бердәм идек,” – ди әтием.

Кешелеклелек, чын дуслык үзебездән тора. Яшьтәшләрем, дуслыкның, гомернең кадерен белик. Күкләребез аяз, тормышлар имин булсын!

Шиһапова Рәмзия, Кукмра 3 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы